31. «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның



5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 226648-7 номерлы федераль закон проекты турында (сатып алулар буенча комиссия әгъзалары тарафыннан мәгълүмат бирү өлешендә).

32. «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 225095-7 номерлы федераль закон проекты турында (куллану кооперациясе оешмаларының сатып алуларда катнашуы өлешендә).

33. Россия Федерациясе Торак кодексының 179 статьясына региональ операторның Россия кредит оешмаларындагы региональ оператор счетында булдырыла торган капиталь ремонт фондының вакытлыча ирекле акчаларын урнаштыру бурычын билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 217987-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

34. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 306.2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 267529-7 номерлы федераль закон проекты хакында (бюджет процессында катнашучыга бюджет буенча мәҗбүр итү чараларын куллану турында хәбәрнамә күчермәсен җибәрү өлешендә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2017 елның 19 октябре
№ 1969-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 2094. Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2018 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2018 елга

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планын расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2017 елның 19 октябре
№ 1971-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2017 елның 19 октябрендәге
1971-V ДС номерлы
карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2018 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чаралар планы

| № т/б | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәре | Гамәлгә ашыру буенча чаралар | Башкару вакыты | Башкару өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Парламентның сайлаучылар һәм иҗтимагый институтлар белән элемтәләрен ныгыту, депутатларның тормыш-көнкүрешнең үзәгендә, аеруча кыен хәлләр еш килеп туа торган урыннарда булуы бик мөһим. | 1.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары беркетелгән сайлау округларында эш. Гражданнарны кабул итү.<br>1.2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, җәмәгать берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү | ел дәвамында | ТР ДС депутатлары |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. | Халык белән эшләгәндә, безгә муниципаль җирлекләрнең, шулай ук җирле иҗтимагый үзидарәнең киң мөмкинлекләреннән файдаланырга кирәк. Җәмәгать урыннарын булдыруда һәм әлеге мәйданчыкларда төрлечә актив эшчәнлек алып баруда гражданнарның катнашу рәвешләрен арттыру юнәлешендә эшләү шарт. Гражданнар башлангычларына нигезләнгән проектларда халыктан кергән 1 сумга республикадан 4 сум бүлеп бирүгә корылган инструменттан файдалану уңай нәтиҗә бирә. Гражданнарны җирлек әһәмиятендәге мәсьәләләрне шушындый юл белән хәл итүгә тарту эше Арча, Балтач, Кукмара, Мөслим районнарында яхшы оештырылган. Әйтергә кирәк, программаны гамәлгә ашыра башлаганнан алып бюджет хисабына финанслау гомумән алганда 2 миллиард сумнан артып китте. Шушы акчага яңа юллар, күперләр, балалар һәм спорт мәйданчыклары, халыкка кирәкле башка объектлар төзелде. | 2.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетының киңәйтелгән утырышында аерым муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкилләре катнашында «Татарстан Республикасы территориясендә территориаль иҗтимагый җирле үзидарәләрне үстерү турында»гы мәсьәләне карау | 2018 елның II кварталы | А.Г. Хәбибуллин |
| 3. | Татарстанлыларның республика тормышында катнашуы үсешебезгә этәргеч бирүче бәрәкәтле көчкә әверелергә тиеш. Бу эштә массакүләм мәгълүмат чараларына һәм Интернет ресурсларга зуррак роль бирү кирәк. Технологик алгарыш кешеләрнең гадәтләренә, аралашу культурасына үзгәрешләр кертә. Мобиль җайланмалар, мәгълүматтан файдаланучының һәм аның таралышының төп чыганагы булу белән беррәттән, социаль активлык чарасына да әверелделәр. Массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлегендә төп | 3.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы гамәлгә куючыларының берсе булган «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләренең эшчәнлеге турында» 2017 елның | 2018 елның марты | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | игътибарны контентның сыйфатына, аның таралыш ысулларына һәм җәһәтлегенә юнәлтергә кирәк.<br>Кешеләрнең мәнфәгатьләре туктаусыз үзгәреш кичерүен һәм дөнья трендларының көчәюен исәпкә алу зарур. Мәгълүмат тарату каналларының үзгәрүе һәм күптөрлелеге «Татмедиа» Республика агентлыгы алдына мәгълүмат мәйданын булдыруда үзенең нинди роль уйнарга тиешлеген кабаттан карап тикшерү бурычын куя. Бу мәйданның, күпкырлы, иҗади эшчәнлегебезне чагылдырып кына калмыйча, халык белән бәйләнеш урнаштыруда нәтиҗәле чара булуы да таләп ителә. | 27 гыйнварындагы 1596-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын үтәү барышы хакында»гы мәсьәләне карау | | |
| | | 3.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсен үстерү һәм «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы эшчәнлеге турында»гы мәсьәләне карау. | 2018 елның мае | Р.И. Вәлиев |
| | | 3.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары белән «турыдан-туры элемтә» оештыру | ел дәвамында | Р.Г. Макуева |
| 4. | Республикада милләтара һәм динара элемтәләрнең, этномәдәни үсешнең югары дәрәҗәдә булуы Татарстан халыкларының өченче съездында һәм Бөтендөнья татар конгрессының алтынчы съездында ачык чагылыш тапты.<br>Хакимият органнарына Татарстан халыклары ассамблеясе һәм Бөтендөнья татар конгрессы белән бергәләп әлеге абруйлы форумнар тәкъдим иткән барлык чаралар комплексын җентекләп эшләү зарур.<br>Алга таба да дәүләтнең милли сәясәтен гамәлгә ашыру | 4.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан халыклары ассамблеясе һәм Бөтендөнья татар конгрессы чараларында катнашулары | 2018 ел дәвамында | И.И. Шәрипов<br>Р.З. Закиров |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | программалары эчтәлеген һәм этно-конфессиональ өлкәдә мониторинглау эшләрен алып баруны камилләштерергә кирәк. | | | |
| 5. | Дәүләт телләрен һәм туган телләрне өйрәнүгә өстенлек бирүне саклап калган хәлдә, республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгына рус телен өйрәнүнең һәм белүнең югары дәрәҗәсен тәэмин итүгә игътибарны арттырырга кирәк.<br>Аерым алганда, республикада игълан ителгән Лев Николаевич Толстой елы кысаларында алып барылган эш моңа ярдәм итәчәк.<br>Шуның белән бергә, Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак, татар телен укыту методикасын, шулай ук укытучылар әзерләүне һәм аларга яңадан әзерлек бирүне, шул исәптән кабат төзелә торган Милли педагогия институты базасында да бу эшне камилләштерү зарур.<br>Телләрне өйрәткәндә башлыча коммуникатив күнекмәләрне үстерү таләп ителә.<br>Бу бурычлар республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы алдында бер генә тапкыр куелмады инде. Әмма башкарыла торган эшнең нәтиҗәлелеге һаман да югары түгел, һәм гражданнар нигезле рәвештә моңа ризасызлык белдерә.<br>Җаваплылык үзәге буларак, министрлыкка тиешле нәтиҗәләр ясарга һәм кирәкле чаралар күрергә кирәк. | 5.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең Лев Толстой елы кысаларындагы чараларда катнашулары. | 2018 ел дәвамында | ТР ДС депутатлары |
| | | 5.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасында Лев Толстой елы йомгаклары турында»гы мәсьәләне карау. *(Л.Н. Толстой исемендәге музей-белем бирү үзәгендә булып)* | 2018 елның декабре | Р.И. Вәлиев |
| 6. | Республикабызның гына түгел, гомумән бөтен Россиянең кадерле тарихи ядкаре – Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын торгызу, шулай ук Болгар ислам академиясе биналары комплексын төзү бөтен халык катнашкан уртак эш, җәмгыятьтәге татулык | 6.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының республикада уздырыла торган дини чараларда катнашулары | 2018 ел дәвамында | ТР ДС депутатлары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | чагылыш тапкан гамәл булды.<br>Академия, һичшиксез, алдынгы фәнни һәм рухи үзәккә әйләнеп, традицион исламны ныгытуга зур өлеш кертергә тиеш.<br>Без киләчәктә дә традицион конфессияләрнең радикальлеккә һәм катгый кире кагуның теләсә-кайсы рәвешенә каршы көрәшүенә, җәмгыятебездә барган рухи-әхлакый үсештә үз рольләрен арттыруга юнәлтелгән тырышлыгына элекке төстә ярдәм күрсәтәчәкбез.<br>Төрле этник төркемнәр һәм диннәр вәкилләренең үзара файдалы багланышлары һәм хезмәттәшлеге, республикадагы милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне ныгыту, илебездән читтә яшәүче ватандашларга булышлык күрсәтү — барлык дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының мөһим бурычы. | | | |
| 7. | Тарихи-мәдәни мирасны саклап калу эше республикада һәрчак игътибар үзәгендә. Матди булмаган мәдәни мирас турында закон кабул ителде.<br>Успение соборының, Свияжск утрау-шәһәрчеге монастыреның ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүе илебезнең зур казанышы булды.<br>Бу исә галимнәрнең, археологларның, реставраторлар һәм төзүчеләрнең, хезмәт коллективларының һәм инде, әлбәттә, Минтимер Шәрип улы Шәймиев җитәкләгән «Яңарыш» фондының күпьеллык тырыш хезмәтенең закончалыклы нәтиҗәсе булып тора.<br>Россиянең Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән 29 объектыннан 3 объект безнең республикабыз территориясендә урнашкан. ЮНЕСКОның таләпләре | 7.1. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы мониторингы<br><br>7.2. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын әзерләү (бөтендөнья мирас объектларының сакланылыш тәэмин итү өлешендә) | 2018 ел дәвамында<br><br>2018 елның IV кварталы | Р.И. Вәлиев<br><br>Т.П. Ларионова |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | артуны исәпкә алып, республиканың Дәүләт Советына әлеге объектларга мөнәсәбәтле рәвештә аларның саклануын, бөтенлеген һәм борынгылыгын законнар нигезендә тәэмин итү чараларын карау зарур.<br>Тупланган тәҗрибәгә таянып, тарихи-мәдәни мирас объектларында археологиятикшеренү һәм торгызу эшләрен, шулай ук төрле халыкара проектларда катнашуны дәвам итәргә кирәк. | | | |
| 8. | Күпмилләтле халкыбызның ментальлеге, аның рухы, үзенчәлекле традицияләре мәдәнияттә чагылыш таба. Аның киң мәгънәсен ачу гаять мөһим.<br>Мәдәният ул — матди, рухи мирасны саклап калудан тыш, кешеләрне берләштерүче рухи хәзинәләр, яңа мәдәни продуктлар булдыру.<br>Мәдәният хәзерге үсеш дәрәҗәсендә мәгариф системасы, туристлык, спорт өлкәсе, архив һәм китапханә эше белән тыгыз берлектә булырга тиеш.<br>Мәдәниятнең үткәнгә генә түгел, киләчәккә дә карап эш йөртүе, замана таләпләренә җавап бирүе мөһим. | 8.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында «Авылда мәдәният оешмалары (учреждениеләре) челтәрен үстерү турында» гы мәсьәләне карау<br><br>8.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасында музыка сәнгатен үстерү турында»гы мәсьәләне карау *(Татарстан Республикасы Композиторлар союзында, И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка училищесында булып)* | 2017 елның ноябре<br><br>2018 елның апреле | Р.И. Вәлиев<br><br>Р.И. Вәлиев |
| 9. | Быел тулаем төбәк продукты үсеше 4 процент тирәсе тәшкил итте.<br>Тышкы санкцияләрнең озак вакыт дәвам итүе шартларында киләчәк үсеш өчен | 9.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, | 2017 елның октябре | ТР ДС комитетлары рәисләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | эчке резервларны активлаштыру гаять мөһим. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары каршындагы эксперт советлары утырышларында «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын һәм 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен фаразлауның төп параметрлары хакында һәрьяклап фикер алышу | | |
| 10. | Шуның белән бергә алга таба эзлекле төстә энергиянең альтернатив чыганакларыннан файдалануга күчү зарур.<br>Бүгенге көндә республикада билгеләнгән күләме 100 МВт суммар көчәнешле җил парклары төзү проектын гамәлгә ашыру буенча эш алып барыла. | 10.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Энергиянең альтернатив, экологик яктан чиста чыганакларын үстерү турында»гы мәсьәләне карау | 2018 елның I кварталы | Т.Г. Һадиев |
| 11. | Хәзерге заман шуны таләп итә: территорияләрне үзара нәтиҗәле үстерү һәм хезмәт ресурсларын бербересендә файдалану максатларында муниципалитетлар үзара сөйләшүләр алып барырга һәм билгеле бер килешүләргә ирешергә тиеш.<br>Илебез ИТ-секторының перспективалы үсеш зонасы булып торучы «Иннополис» махсус икътисадый зонасын һәм шул ук исемдәге шәһәрне үстерү эше дәвам итә.<br>Биредә цифрлы икътисад | 11.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Бюджет, салымнар һәм финанс комитетының күчмә утырышында «Махсус икътисадый зоналарда салым ташламалары бирүнең нәтиҗәлелеге турында»гы мәсьәләне карау | 2018 елның III кварталы | Л.А. Якунин |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | үсешенә бәйле тикшеренүләр һәм хезмәтләр тупланырга тиеш.<br>Республикада бизнесны үстерү инфраструктурасы булдыру эше үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә. Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә аларның резидентлары өлеше инде 9 проценттан артып китә. Безгә әле үсеш өчен мәйдан киң. Сүз, әлбәттә, муниципаль сәнәгать мәйданчыклары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру турында бара. Бу аеруча Мамадыш районындагы «Нократ», Чаллы шәһәрендәге «Үсеш» һәм Яңа Чишмә районындагы сәнәгать мәйданчыклары эшенә кагыла.<br>Республика әлеге сәнәгать мәйданчыкларын төзүгә бик күп акча бүлеп бирә. Һәм безнең алардан билгеле бер нәтиҗә таләп итәргә тулы хакыбыз бар. | | | |
| 12. | Һәр муниципалитет территориясендә бизнес өчен конкурентлык мохите тудыру һәм аны стимуллаштыру мөһим.<br>Мәнфәгатьләр каршылыклары килеп чыгу һәм конкурентлыкның булмавы җирле бизнесның үсешенә тоткарлык ясый һәм, нәтиҗәдә, ул бөтенләй юкка чыга.<br>Без эшкуарларга үз бизнесын башлап җибәрү һәм үстерү, Татарстан икътисадына табыш китерә торган инвестицияләр җәлеп итү, килеп туган кыенлыкларны тиз арада һәм нәтиҗәле хәл итү өчен тиешле шартлар тудырырга тиеш. | 12.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты белән Законнар һәм хокук куллану практикасы мониторингы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләсе буенча парламент тыңлаулары уздыру | 2017 елның декабре | Ю.З. Камалтынов<br>Р.Т. Борһанов |
| 13. | Бизнеска тагын да зуррак мөмкинлекләр тудырырга һәм административ киртәләрне киметергә кирәк. Тагын бер кат басым ясап әйтәм, контроль-күзәтчелек органнарының төп бурычы – бизнеска штрафлар салу түгел, ә бәлки эшкуарлар | 13.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында «Татарстан Республикасы | 2018 елның мае | Ш.Ш. Яһудин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белән бергәлектә, алдан тикшерүләр уздыру, кисәтүләр һәм искәртүләр белдерү кебек механизмнарны тулы күләмдә файдаланып, закон бозу очракларын бетерү. | дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында һәм җирле үзидарә органнарында норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында»гы контроль мәсьәләне карау | | |
| 14. | Сәнәгать инфраструктурасын үстерү барышында җәмәгать урыннары санын арттыру да зарур. Территорияләрне үстерүгә, архитекторлар, шәһәр төзүчеләре, инвесторлар һәм гражданнарның бердәм фикерен исәпкә алып, комплекслы якын килүне тәэмин итү гаять мөһим. Территорияләрнең үзара бәйләнешен арттыруга юнәлтелгән эшне дәвам итү зарур.<br>Шул ук вакытта киләчәктә төзеләчәк транспорт челтәрләре республикада инде гамәлдә булган һәм төзелүче логистика үзәкләре аша узарга тиеш. | 14.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты тарафыннан «Татарстан Республикасының икътисадый үсеш нигезе буларак территорияләрне үстерү» мәсьәләсе буенча «түгәрәк өстәл» уздыру | 2018 елның апреле | Р.Т. Борһанов |
| 15. | Моннан тыш, Экология елы кысаларында республикада 1200 чүплек юкка чыгарылды, 10 мең км озынлыкта яр буе полосасы һәм меңнәрчә су объектлары чистартылды, 4 мең гектар мәйданда 20 миллион агач үсентесе утыртылды, табигатьне саклау буенча төрле чараларда һәм акцияләрдә миллионнан артык татарстанлы катнашты.<br>Безнең бурыч — икътисадны үстерү һәм әйләнә-тирә мохитне саклау арасындагы тигезлекне югалтмау.<br>Экология өлкәсендәге зур җаваплылык икътисадның реаль секторлары предприятиеләренә төшә.<br>Республиканы «яшел икътисад» принциплары нигезендә үстерү өчен Казан шәһәрендә коммуналь каты калдыкларны термик | 15.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) | 2017 елның IV кварталы | Т.Г. Һадиев |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | эшкәртү буенча завод төзү планлаштырыла.<br>Бу исә Казан шәһәре янындагы әһәмиятле җир кишәрлекләрен хуҗалык әйләнешеннән алу проблемасын хәл итү, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны күп тапкырларга киметү, Швейцария, Германия, Голландия һәм Япония кебек илләрдәгечә коммуналь каты калдыкларны җиргә күммичә, тулысынча эшкәртү мөмкинлеге бирә.<br>Тулаем алганда, «яшел икътисад» теория булып кына калмыйча, көндәлек кулланылыштагы көнкүреш күнекмәләренә әйләнергә тиеш. | үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2014 елның 29 декабрендәге 458-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау<br><br>15.2. Депутатларның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең ел саен үткәрелә торган «Агач утырту көне» акциясендә, Казан шәһәре территориясен санитар чистарту буенча өмәләрдә катнашулары | ел дәвамында | ТР ДС депутатлары, ТР ДС Аппараты хезмәткәрләре |
| 16. | Без төзелештә өлешле катнашудан зыян күрүчеләр проблемаларын хәл итү буенча эшне актив рәвештә дәвам итәбез. Чараларның тулы бер комплексы үткәрелә.<br>Нәтиҗәдә, быел 275 кеше өчен 2 йорт тапшырылды, 12 объектта төзелеш эшләре алып барыла. Шулардан ел ахырына 938 кеше өчен кимендә 6 йорт куллануга тапшырылачак.<br>Моннан тыш, без төзелештә өлешле катнашучылар проблемасын хәл итүне дәвам итү максатларында инвестиция проекты өчен республикабыз башкаласында 17 га мәйданда җир кишәрлеге бүлеп бирү турында карар кабул иттек. | 16.1. Төзелештә өлешле катнашудан зыян күрүчеләрнең инициатив төркемнәре вәкилләре белән һәрдаим очрашулар уздыру. Объектларны төзеп бетерү проблемасын хәл итү эшләрен җайга салу | 2018 елның II кварталы | А.В. Прокофьев |
| 17. | Соңгы елларда торак-коммуналь комплексына тиешле күләмдә акча бүлеп бирелә. Без гамәлдәге капиталь төзекләндерү программасы кысаларында күпфатирлы торак фондының торышын күпкә яхшыртуга ирештек. Әмма моның белән генә республика халкының мөрәҗәгатьләре саны кимеми. | 17.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем | 2017 елның декабре | Р.Т. Борһанов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Шикаятьләрнең күпчелеге идарәче компанияләр эшчәнлегенә бәйле. Аларда күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына, түләүләрнең тиешле дәрәҗәдә аңлаешлы булмавына кагылышлы мәсьәләләр күтәрелә.<br>Уздырылган барлык тикшерүләр чыгымнарның нәтиҗәсез сарыф ителүен генә түгел, ә бәлки максатчан тотылмавын да дәлилли. Фатир өчен түләү документларында бик еш хаталар була, исәп-хисап счетларына нигезсез рәвештә өстәмә хезмәтләр кертелә.<br>Болар барысы да халыкта тискәре мөнәсәбәт тудыра. | сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә лицензия контроленең нәтиҗәлелеген арттыруның йомгаклары һәм шартлары турында»гы мәсьәләне карау<br><br>17.2. Торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге проблемалар хакында КПРФ фракциясе утырышларында фикер алышу. | 2018 ел дәвамында | Х.Г. Миргалимов |
| 18. | Агросәнәгать комплексы республика үсешенең иң әһәмиятле тармакларыннан берсе булып тора.<br>Тулаем төбәк продуктының 11 проценты азык-төлек сәнәгате белән берлектә агросәнәгать комплексына туры килә. | 18.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының һәм «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек | 2018 елның феврале | Т.Г. Һадиев |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «2017 елда һәм 2018 елның<br>I квартал план чорына «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын үтәү йомгаклары хакында»гы мәсьәләне карау | | |
| 19. | Республикада хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм күрсәтү буенча зур эш уздырыла һәм ул үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә.<br>Узган елда республикадагы тулаем авыл хуҗалыгы продуктлары күләменең яртысыннан артыгы алар тарафыннан җитештерелде.<br>Фермер хуҗалыклары күрсәткечләре тотрыклы рәвештә үсә. Узган елда тулаем продукт күләме буенча аларда үсеш 16 процент тәшкил итте.<br>Республика парламенты Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин һәм авыл хуҗалыгы министры Марат Готыф улы Әхмәтов тарафыннан авылларда эшлекле активлыкны үстерү буенча алып барылган уңай эшчәнлекне аерып билгеләп үтәргә кирәк. Урындагы киңәшмәләр һәм эшнең башка рәвешләре яхшы нәтиҗә бирә. | 19.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының һәм «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Татарстан Республикасы территориясендә | 2018 елның II кварталы | Т.Г. Һадиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында»гы мәсьәләне карау | | |
| | | 19.2. Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерциягә карамаган дача берләшмәләренә ярдәм итү программасын камилләштерү һәм аны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләү | 2018 елның II кварталы | Х.Г. Миргалимов |
| 20. | 20. Авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртү һәм сату мәсьәләләрен хәл итүдә авылларда кулланучылар кооперацияләрен үстерү зур ярдәм булачак. Республикада 46 кооператив булдырылды. Безнең алда аларның санын икеләтә арттыру бурычы тора. Кооперативлар һәр районда булырга тиеш. | 20.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының һәм «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Авылда куллану кооперациясен үстерүгә юнәлдерелгән чаралар турында»гы мәсьәләне карау | 2018 елның IV кварталы | Т.Г. Һадиев |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21. | Агросәнәгать комплексы өлкәсендә продуктларның конкурентлыкка сәләтле булуларын тәэмин итү өчен дөнья практикасының иң яхшы үрнәкләрен һәм югары технологияләрне актив рәвештә куллanышка кертергә кирәк.<br>Тиз үзгәрүче дөнья хезмәт базарына да яңа таләпләр куя.<br>Иң беренче чиратта сүз хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру турында бара. Барлык тармакларда да, аеруча бюджет өлкәсендә, сакчыл җитештерү принципларын һәм инструментларын куллану зарур. | 21.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының һәм «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы продукциясен гамәлгә ашыруның икътисадый нәтиҗәлелеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында»гы мәсьәләне карау | 2018 елның III кварталы | Т.Г. Һадиев |
| 22. | Заманча бизнесның яңа тенденциясе булып «офистан тыш эшләү» тора. Читтән торып эшләүгә күчү моңа кадәр хезмәт базарында катнаша алмаучыларга, мәсәлән, бала карау буенча ялда булган яшь әниләр яисә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләргә, эшкә урнашу мөмкинлеге бирә. | 22.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетында «Татарстан Республикасында аерым категориядәге гражданнарны эш белән тәэмин итүнең яңа рәвешләрен булдыру өлешендә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен үстерү турында»гы мәсьәләне карау | 2018 елның IV кварталы | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 23. | Нәкъ менә мәгърифәт дөньяны үзгәртергә сәләтле. Сабыйларыбызның киләчәктә уңышлы үсешенә нигез булачак белем һәм күнекмәләр нәкъ менә кечкенәдән үк бирелә.<br>Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, шуны истә тотып, аеруча телләр өйрәтүгә зур игътибар биреп эшләргә тиешле.<br>Берничә тел белү – конкурентлыкта өстенлек ул. Мәктәпләребездә белем бирүнең сыйфатына аерым игътибар юнәлтү таләп ителә. Ул мәгариф өлкәсе хезмәткәрләренең оештыруда куйган тырышлыгына түгел, бәлки мәктәп тәмамлаган укучыга ихтыяҗ дәрәҗәсенә, аның киләчәктә белгеч буларак ирешкән уңышларына карап бәяләнергә тиеш.<br>Мәгариф системасында эш сыйфатын яхшыртуның нигезен педагогның һөнәри осталыгы, аның белем һәм методика өлкәсендә заман таләпләренә туры килергә омтылуы, укучыларның сәләтләрен һәм мөмкинлекләрен күрә һәм үстерә белүе тәшкил итәргә тиеш.<br>Бу – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы җаваплылыгындагы даирә.<br>Укытучыларның квалификациясен күтәрү формаларын камилләштерү, аларның белем дәрәҗәсен бәяләүнең яңа объектив методларын куллану зарур.<br>Район башлыкларына һәр мәктәптә белем бирүнең сыйфатын мониторинглау эшен башларга кирәк.<br>Шул ук вакытта әлеге мәгълүмат барлык ана-аналар өчен ачык һәм аңлаешлы булырга тиеш. | 23.1. КПРФ фракциясе утырышында «Татарстан Республикасында белем бирү. Проблемалар һәм перспективалар. Белем бирү сыйфаты дәрәҗәсе» мәсьәләсе буенча фикер алышу | 2017 елның IV кварталы | Х.Г. Миргалимов |
| | | 23.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында белем бирүне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында еллык доклады | 2018 елның декабре | Р.И. Вәлиев |
| | | 23.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләрен «Эшлекле рус сөйләм культурасы: норматив, коммуникатив һәм этик аспектлар», «Эшлекле татар теле» юнәлешләре буенча квалификацияне күтәрү курсларында укыту. | 2017 елның IV кварталы | ТР ДС Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 24. | Бүгенге көнгә кадәр предприятиеләр, югары уку йортлары һәм тармак министрлыкларының республика Фәннәр академиясе белән нәтиҗәле үзара эшчәнлек алып бару механизмы эшләнмәгән. Фәннәр академиясен әлегә фәнни тикшеренүләр һәм гамәли характердагы эшләнмәләр туплану үзәге дип әйтеп булмый. Башкарылган хезмәтләрнең төп күләменә ихтыяҗ бик аз. Академиянең мөмкинлекләре гаять зур. Аннан нәтиҗәле файдаланырга кирәк.<br>Хөкүмәтебезгә киләсе елга һәм аннан соңгы ике елга Фәннәр академиясе өчен гамәли тикшеренүләр планын, аны Академиянең дәүләт бурычы исемлегенә кертеп, формалаштыруны контрольгә алуны тапшырам. | 24.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасында фәнне үстерү һәм фәнни эшчәнлек турында»гы мәсьәләне карау *(Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә)* | 2018 елның ноябре | Р.И. Вәлиев |
| 25. | Мәгариф системасының өстенлекле һәм аеруча катлаулы бурычы – балаларга тәрбия бирү мәсьәләсе. Белем бирү һәм тәрбиянең бер-берсе белән тыгыз бәйләнеше турында сөйләп кенә калмыйча, моны гамәлдә тормышка ашырырга кирәк.<br>Әлеге эш чаралар һәм акцияләр уздыруга гына кайтып калмасын. Һәрбер укытучы һәм сыйныф җитәкчесе тәрбияче булырга тиеш.<br>Үзара ышаныч һәм хөрмәткә нигезләнгән тәртип, яшь татарстанлылар аңына оста итеп, бала күңеленә каты бәрелмичә традицион рухи кыйммәтләр төшенчәсен, сәламәт яшәү рәвешенә һәм иҗади эшчәнлеккә омтылыш сеңдерү – шәхес, зур һәм көчле ил гражданы формалаштыруга җирлек булып тора.<br>Һичшиксез, тәрбия процессында төп роль гаиләгә бирелә. Нәкъ менә монда гореф-гадәтләребез буыннан буынга тапшырыла килә, Ватаныбызга мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре тәрбияләнә. | 25.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләүне үстерү турында»гы мәсьәләне карау | 2018 елның июне | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26. | Шул ук вакытта поликлиникаларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итәсе бар әле. Аны комплекслы рәвештә – цифрлы, оештыру һәм кадрлар технологияләрен бер үк вакытта файдаланып хәл итү зарур. Республикада беренчел звеноны үстерүгә аеруча зур басым ясала, авыруларның 80 проценты нәкъ менә шушы оешмаларга мөрәҗәгать итә һәм дәвалана. Быел өр-яңа программа эшли башлады. Ике ел эчендә Татарстанның барлык поликлиникаларны капиталь төзекләндерү, аларны нормаларга туры китерү һәм заманча җиһазлар белән тәэмин итү эшен башлау планлаштырыла. | 26.1. КПРФ фракциясе утырышында «Татарстан Республикасы поликлиникаларында һәм стационар хастаханәләрендә күрсәтелә торган түләүле һәм түләүсез медицина хезмәт күрсәтүләренең сыйфаты һәм саны турында»гы мәсьәлә буенча фикер алышу | 2018 елның III кварталы | Х.Г. Миргалимов |
| 27. | Хезмәткә сәләтле халыкның сәламәтлегенә аеруча игътибар бирергә кирәк. Сәламәтлек саклауның нәтиҗәле юнәлешләренең берсе – предприятиеләр хисабыннан тулысынча медицина тикшеренүе узуны оештыру һәм һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәсендә куркыныч авырулы булган хезмәткәрләргә онкоскрининглар уздыру тора. | 27.1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең күчмә утырышында «Хезмәткә сәләтле яшьтәге халыкның сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау (Татарстан Республикасындагы предприятиеләрнең берсе мисалында) | 2018 елның I кварталы | С.М. Захарова |
| 28. | Республикада спорт инфраструктурасын актив үстерү, ГТО системасын гамәлгә кертү, спорт чараларын еш уздыру сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда уңай этәргеч бирә. | 28.1. Депутатларның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең ГТО нормаларын тапшыруда, башка спорт чараларында катнашулары | ел дәвамында | Б.Р. Хәсәнов |
| 29. | Социаль яклау өлкәсендә мөһим юнәлешләр булып олы яшьтәге гражданнарга социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм әлеге хезмәтләрдән һәркемнең файдалануын тәэмин итү, бу гражданнарны укыту, инвалидларны эшкә урнаштыру, ятим балалар турында кайгырту, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларның җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә катнашуы өчен шартлар булдыру тора. | 29.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эшләре комитетының уртак утырышында «2025 елга кадәр Россия Федерациясендә өлкән буын гражданнар мәнфәгатьләрендәге эшләрнең стратегиясен Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау | 2017 елның ноябре | С.М. Захарова |
| | | 29.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге эшләрнең республика стратегиясен гамәлгә ашыру турында» 2017 елның 11 апрелендәге 17 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты карарын үтәү хакында»гы мәсьәләне карау | 2018 елның II кварталы | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 30. | Һәр көнне дөньяда тормышыбызны тамырдан үзгәртергә сәләтле яңа технологияләр барлыкка килә, яңа идеяләр туа тора. Боларның барысын да кешеләр башкара.<br>Без зур мөмкинлекләр чорында яшибез. Республикабыз да зирәк акыллы кешеләргә бай.<br>Хыялланыгыз, иҗат итегез, масштаблы планнар корыгыз һәм һәрчак белем туплауны, өйрәнүне дәвам итегез. Бары тик шул очракта гына алга хәрәкәт тукталмас! | 30.1. 2017/2019 елларга дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты программасы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратында дәүләт граждан хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү | ел дәвамында | ТР ДС Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| | | 30.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләренең ел саен үткәрелә торган «Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре» республика конкурсында катнашулары | ел дәвамында | ТР ДС Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 31. | | 31.1. Татарстан Республикасы Президентының 2018 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәләре тарафыннан гамәлгә ашыру (аерым планнар буенча) | ел дәвамында | Ю.З. Камалтынов<br>Х.Г. Миргалимов<br>Р.З. Закиров<br>Т.П. Ларионова |



# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**2095. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Т. Борһанов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 390-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (тапшырылган вәкаләтләрне төгәлләштерү өлешендә) алдан карау турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 390-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә алу өчен Татарстан

Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Күрсәтелгән закон проектын Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясындагы 3 өлеше нигезендә бәяләмә алу өчен Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты күрсәтелгән закон проектын 2017 елның 29 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2017 елның 4 октябре
№ 502-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 2096. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Т. Борһанов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 391-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен һәм күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның региональ программасына үзгәрешләр кертү тәртибен төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 391-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты күрсәтелгән закон проектын 2017 елның 29 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2017 елның 4 октябре
№ 503-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 2097. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 392-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 63, 64 статьялары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 392-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кабул итәргә.

2. «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 392-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан

Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка комитетларына, аларны закон проекты буенча башкарышучылар итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү өчен закон чыгару инициативасы хокукына ия башка субъектларга, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

3. Башкарышучы комитетлар «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 392-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектының түбәндәге аерым нигезләмәләрен карауны гамәлгә ашыралар дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты – Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Гомумдәүләт мәсьәләләре», «Дәүләт һәм муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү», «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар» бүлекләрен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты – Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Милли оборона», «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге» бүлекләрен, «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегенең «Суд системасы» бүлекчәсен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты – Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Милли икътисад», «Торак-коммуналь хуҗалык» бүлекләрен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты – Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Әйләнә-тирә мохитне саклау» бүлеге, «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге» бүлегенең «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданнар оборонасы» бүлекчәсен, «Милли икътисад» бүлегенең «Минерал-чимал базасын торгызу», «Авыл хуҗалыгы һәм балыкчылык», «Су хуҗалыгы», «Урман хуҗалыгы» бүлекчәләрен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты – Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Сәламәтлек саклау», «Социаль сәясәт»,



«Физик культура һәм спорт» бүлекләрен, «Мәгариф» бүлегенең «Яшьләр сәясәте» бүлекчәсен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты – Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Мәгариф», «Мәдәният, кинематография», «Массакүләм мәгълүмат чаралары» бүлекләрен, «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегенең «Фундаменталь тикшеренүләр» бүлекчәсен.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы бәяләмәләрен 2017 елның 13 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты 2017 елның 17 октябренә кадәр «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 392-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектына җыелма бәяләмә әзерләргә, 2017 елның 31 октябренә кадәр күрсәтелгән закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына 2017 елның 10 октябрендә 10 сәгатьтә «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 392-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты буенча парламент тыңлаулары уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2017 елның 4 октябре
№ 504-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 2098. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 393-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 393-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карауга кабул итәргә.

